| Республика Татарстан<br>нделеевский муниципальный район<br>Исполнительный комитет<br>Татарско-Челнинского сельского<br>поселения | Татарстан Республикасы<br>Менделеев муниципаль районы<br>Татар-Чаллысы авылы җирлеге<br>башкарма комитеты |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 24 июленнән №14

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
2021 елның 26 февраленнән
35 нче номерлы
Татар Чаллысы авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына
үзгәрешләр кертү турында

2013 елның 25 июненнән 50-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында Кодексының" 37 статьясы, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында" Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 29 гыйнварындагы ПУ-61 номерлы Указы нигезендә Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Татар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 26 февралендәге 5 нче номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13 пунктындагы 3 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла. Муниципаль хезмәткәр үлсә (һәлак булса), яисә муниципаль хезмәткәр хәбәрсез югалган дип танылган яисә законлы көченә кергән суд карары белән аның вафат булуы игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр үлем (һәлак булу) көненнән яки суд карары законлы көченә кергән көннән соң килгән көндә муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты бинасының мәгълүмат стендында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ "Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык Т.П. Кузнецова